МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.04.2019 г.Казань № 226

ТР Юстиция министрлыгында 2019 елның 24 апрелендә 5531 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 10 августындагы 465 номерлы, 2018 елның 14 маендагы 363 номерлы, 2018 елның 10 октябрендәге 935 номерлы, 2019 елның 22 гыйнварындагы 45 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте

күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр в.б. Р.Ф.Вәлиуллов

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
03.04.2019 № 226 боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар булып пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, бүтән нигезләрдә пенсия алучы яки «Иминият пенсияләре турында» федераль законның 8 статьясының беренче өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирүче яшькә җиткәч эше (хезмәте) өчен гомере буе түләү алучы пенсионерлар, Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, гаиләләренең җан башына исәпләгәндә уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән пенсионерның яшәү минимумы зурлыгының 400 процентыннан артмаган һәм мөлкәти тәэмин ителеше «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән гаиләнең (гражданинның) мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ирләр һәм хатын-кызлар) җиткән, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Авыруларны медицина сайлап алуы һәм шифаханә-курорт дәвалавына юллау тәртибе турында» 2004 елның 22 ноябрендәге 256 номерлы боерыгында билгеләнгән тәртиптә бирелгән һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Амбулатор шартларда медицина ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларында кулланыла торган унивикацияләнгән медицина документациясе формаларын һәм аларны тутыру тәртипләрен раслау турында» 2014 елның 15 декабрендәге 834н номерлы боерыгы белән расланган 070/у номерлы формалы белешмә белән расланган шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗлык турында медицина күрсәтмәләре булганда, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә санатор-шифаханә дәвалавына хокукы булмаган гражданнар тора.

1.5 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, № 52, 4920 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» 2001 елның 15 декабрендәге 166-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2001, № 51, 483 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Аз керемле дип тану һәм дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен керемнәрне исәпкә алу һәм гаиләнең җан башына туры килә торган керемен һәм ялгыз яшәүче гражданинның керемен исәпләү тәртибе турында” 2003 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, № 14, 1257 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүмат яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3448 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – «Иминият пенсияләре турында» федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 52, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Инвалидларның хокуклары турында конвенция ратификацияләнүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 49, 6928 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (алга таба – 601 номерлы указ) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен гаиләнең җан башына туры килә торган керемен һәм ялгыз яшәүче гражданинның керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керем төрләре исемлеге турында» 2003

елның 20 августындагы 512 номерлы карары (алга таба – 512 номерлы карар) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, № 34, 3374 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Амбулатор шартларда медицина ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларында файдаланыла торган медицина документациясенең унификацияләнгән формаларын һәм аларны тутыру тәртипләрен раслау турында» 2014 елның 15 декабрендәге 834н номерлы боерыгы (алга таба – 834н номерлы боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 2015, 26 февраль, бастырып чыгару номеры: 0001201502260006);

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» Татарстан Республикасы Законы) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары җыентыгы» журналы, 2004, № 47, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курортта дәвалауны тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курортта дәвалауны тәэмин итү тәртибе (алга таба – ТР МК 97 номерлы карары белән расланган Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2011, № 18, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

2 бүлекнең «Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт» графасында:

2.3 пунктта «3.1» саннарын «2.2.2» саннарына алмаштырырга;

2.4 пунктта «3.1» саннарын «2.2.2» саннарына алмаштырырга;

2 бүлекнең «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.6 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге мәгълүматлар алына:

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнүче, алына торган барлык төр пенсияләрнең һәм башка түләүләрнең күләме турында;

Россия Федерациясе Пенсия фондында булган, физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында;

опека (химаяче) билгеләү һәм опекунның (химаяченең) бала асрауга акча алуы турында (җирле үзидарә органнарыннан);

эшсез сыйфатында теркәү, эшсезлек буенча пособие (стипендияләр һәм башка төрле түләүләр) алу һәм аның күләме турында (Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәтләре дәүләт учреждениеләреннән) (гаилә әгъзалары өчен) (алга таба – Халыкның мәшгульлек үзәкләре);

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

гариза бирүченең гаилә составы турында (вәкаләтле оешмалардан);

күчемсез мөлкәт булуы турында (Росреестрдан);

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм башка төр техниканың булуы турында (вәкаләтле органнардан);

шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре (мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң) булуы турында (вәкаләтле оешмалардан).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Аталган белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алынырга мөмкин.

Идарә (бүлек) мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы күздә тотылмаган документларны тиешенчә федераль башкарма хакимият органнарыннан, бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның, дәүләт хезмәткәренең ялгыш яки хокукка каршы килә торган гамәлен (гамәл кылмавын) документальраслаучы фактны (билгеләрне) ачыклаганда, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә.

Документларны алу ысуллары һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны тапшыру тәртибе әлеге регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый»;

2.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны гамәлдә булу вакыты узгач тапшыру.»;

2 бүлекнең «Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив акт» графасында:

2.8 пунктта «2.1» саннарын «2.3» саннарына алмаштырырга;

2.9 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«2. Мөрәҗәгать итүче гаиләсенең җан башына исәпләгәндә уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән пенсионерның яшәү минимумы күләменең 400 процентыннан артып китүе;

3. Мөрәҗәгать итүченең мөлкәти тәэмин ителү дәрәҗәсе гаиләнең (гражданиннын) гаиләсенең мөлкәти тәэмин ителүенең «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән дәрәҗәсен арттырып җибәрүе.»;

3 бүлектә:

3.4.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Идарә (бүлек) белгече электрон формада түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган документларны ала:

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнүче, алына торган барлык төр пенсияләрнең һәм башка түләүләрнең күләме турында;

Россия Федерациясе Пенсия фондында булган, физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында;

опека (химаяче) билгеләү һәм опекунның (химаяченең) баланы асрауга акча алуы турында;

эшсез сыйфатында теркәлү, эшсезлек буенча пособие (стипендия һәм бүтән түләүләр) алу һәм аның күләме турында (гаилә әгъзалары өчен);

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында;

мөрәҗәгать итүченең гаилә составы турында;

күчемсез мөлкәт булуы турында;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм башка төр техниканың булуы турында;

шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре (мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң) булуы турында.»;

3.4.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Идарәдә (бүлектә) ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә кую турында (исәпкә куюдан баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр булмаган очракта, Идарә (бүлек) белгече, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада, белешмәләр тапшыру турында гарызнамәләр җибәрә:

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнүче, алына торган барлык төр пенсияләрнең һәм башка түләүләрнең күләме турында (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

Россия Федерациясе Пенсия фондында булган, физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан түләнгән түләүләрнең яки башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

опека (попечительлек) билгеләү һәм опекунның (попечительнең) бала асрауга акча алуы турында (җирле үзидарә органнарыннан);

эшсез сыйфатында теркәлү, эшсезлек буенча пособие (стипендия һәм бүтән түләүләр) алу һәм аның күләме турында (Халыкның мәшгульлек үзәкләреннән) (гаилә әгъзалары өчен);

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

гариза бирүченең гаилә составы турында (вәкаләтле оешмалардан);

күчемсез мөлкәт булуы турында (Росреестрдан);

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм башка төр техниканың булуы турында (вәкаләтле органнардан);

шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре (мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң) булуы турында (вәкаләтле оешмалардан).

Ведомствоара гарызнамә электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешентә формалаштырыла һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ВЭХС) каналлары буенча җибәрелә.

Ведомствоара электрон гарызнамәне электрон документ рәвешендә формалаштыру һәм ВЭХС каналлары буенча җибәрүнең техник мөмкинлекләре булмаганда, ведомствоара гарызнамә кәгазьдә почта аша, бер үк вакытта почта аша яисә курьер ярдәмендә җиткерү юлы белән факс буенча җибәрелә.

Ведомствоара гарызнамә 210-ФЗ номерлы федераль законның 7.2 статьясы таләпләре нигезендә формалаштырыла.

3.4.1 һәм 3.4.2 пунктларда билгеләнә торган процедуралар алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: ведомствоара гарызнамә формалаштыру һәм җибәрү.»;

3.4.3 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.3. Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре 3.4.2 пунктның икенче-унынчы абзацларында күрсәтелгән, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән гарызнамәләр нигезендә соралучы белешмәләрне (документларны) бирә.

3.4.2 пунктта билгеләнә торган процедуралар законнарда билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: гарызнамәгә җавап нәтиҗәсе булган белешмәләр (документлар) яисә соралучы белешмәләрнең булмавы турында Идарәгә (бүлеккә) җибәрелгән хәбәрләмә.»;

3.5 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту турында) турында карар әзерләү һәм кабул итү

3.5.1. Идарә (бүлек) белгече әлеге Регламентның 3.4.1 һәм 3.4.2 пунктларында күрсәтелгән белешмәләр һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 3 нче кушымтасындагы форма буенча ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юлламаны тәэмин итү өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту турында) турында карар проектын рәсмиләштерә;

ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту турында) турында карар проектын кул кую өчен Идарә (бүлек) җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гарызнамәләргә җаваплар килгән көннән соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла, ләкин гаризаны теркәгән көннән соң җиде эш көнненән дә соңга калмыйча.

Процедураның нәтиҗәсе: ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту турында) турында карар проекты.

3.5.2. Идарә (бүлек) җитәкчесе документларны караганнан соң ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә

кую (куюдан баш тарту турында) турында карарны имзалый һәм Идарә (бүлек) белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту турында) турында карар.»;

3.8 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Техник хаталарны төзәтү

Шифаханә-курорт дәвалавына юлламаны тәэмин итү өчен ташламалы шартларда юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту турында) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерү элек бирелгән шифаханә-курорт дәвалавына юлламаны тәэмин итү өчен ташламалы шартларда юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту турында) турында карардагы техник хаталарны (язу, басма, грамматик яки арифметик хаталарны) бетерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Шифаханә-курорт дәвалавына юлламаны тәэмин итү өчен ташламалы шартларда юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту турында) турында карарны үзгәртеп рәсмиләштерү техник хатасы булган, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак тапшырылган документ (мондый документ бирелү очрагында) белән теркәлгән гариза (гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентка 4 нче кушымтада китерелә) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.8.1. Идарә (бүлек) белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гаризаларны теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

элегрәк кабул ителгән шифаханә-курорт дәвалавына юлламаны тәэмин итү өчен ташламалы шартларда юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту турында) турында карардагы техник хатаны төзәтүне күздә тотучы карар рәсмиләштерә;

элегрәк кабул ителгән шифаханә-курорт дәвалавына юлламаны тәэмин итү өчен ташламалы шартларда юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту турында) турында карардагы техник хатаны төзәтүне күздә тотучы карарны имза кую өчен Идарә (бүлек) җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: элегрәк кабул ителгән шифаханә-курорт дәвалавына юлламаны тәэмин итү өчен ташламалы шартларда юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту турында) турында карардагы техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәүгә алынган гариза.

3.8.2. Идарә (бүлек) җитәкчесе элегрәк кабул ителгән шифаханә-курорт дәвалавына юлламаны тәэмин итү өчен ташламалы шартларда юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту турында) турында карардагы техник хатаны төзәтү турында карарга кул куя.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: элегрәк кабул ителгән шифаханә-курорт дәвалавына юлламаны тәэмин итү өчен ташламалы шартларда юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту турында) турында карардагы техник хатаны төзәтү турында имзаланган карар.

3.8.3. Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә элегрәк кабул ителгән шифаханә-курорт дәвалавына юлламаны тәэмин итү өчен ташламалы шартларда юллама белән тәэмин итү өчен исәпкә кую (куюдан баш тарту турында) турында карардагы техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән карар хакында мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысулларның берсе ярдәмендә, почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр җибәреп, «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша хәбәр итә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер көн дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә техник хатаны бетерү турында хәбәр итү.»;

4 бүлектә 4.2 пунктның икенче абзацын көчен югалткан дип танырга;

5 бүлекнең 5.1 пунктындагы беренче-өченче абзацларны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр судка кадәр тәртиптә Идарәнең (бүлекнең) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Идарә (бүлек) җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Идарә (бүлек) җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министр исеменә тапшырыла.

Министр карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.»;

Регламентка 1 нче кушымтада «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә персональ мәгълүматларны эшкәртүгә, шул исәптән җыюга, тәгаенләштерүгә, файдалануга, персональ белешмәләр белән алмашуның мәгълүмат системасында өченче затларга тапшыруга үз ризалыгымны бирәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

Регламентка 4 нче кушымтада:

«(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, ата исеме тулысынча)» сүзләрен «(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

«язмача, смс-хәбәр итеп, электрон почта аша» сүзләрен «почта адресы буенча язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр итеп, «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша» сүзләренә алмаштырырга.»;

6 нчы (белешмәлек) кушымтаның 1 нче бүлегендәге таблицада:

кырык бишенче- кырык җиденче абзацларны киләсе редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «Казан ш. муниципаль берәмлегенең Авиатөзелеш, | 843) 571-58-00 | 420036, Казан ш., Тимирязев ур., 8 й. |

| | | |
|---|---|---|
| Яңа Савин районнарындагы социаль яклау бүлеге | (843)<br>523-75-82 | Usz.Avia@tatar.ru<br><br>420124, Казан ш., Хөсәен Ямашев пр., 37 й.<br>Usz.Novosavin@tatar.ru |
| Казан ш. муниципаль берәмлегенең Вахитов, Идел буе районнарындагы социаль яклау бүлеге | (843)<br>238-10-55<br><br>(843)<br>224-04-20<br>224-20-28 | 420043, Казан ш., Вишневский ур., 10 й.<br>Usz.Vahit@tatar.ru<br><br>420059, Казан ш., Рихард Зорге ур., 39 й.<br>Usz.Priv@tatar.ru |
| Казан ш. муниципаль берәмлегенең Киров, Мәскәү районнары социаль яклау бүлеге | (843)<br>554-47-80<br><br>(843)<br>554-25-47<br>554-36-72 | 420102, Казан ш., Галимҗан Баруди ур., 5<br>Usz.Kirov@tatar.ru<br><br>420102, Казан ш., Галимҗан Баруди ур., 5<br>Usz.Moskov@tatar.ru»; |

кырык сигезенче-илленче абзацларны төшереп калдырырга.